Бөтендөнья балалары, дуслашыгыз!



Сабантуй

БАЛАЛАР ҺӘМ ЯШҮСМЕРЛӘР ГАЗЕТАСЫ

8 апрель, 1995 ел. № 26 (4640)



ДӨНЬЯБЫЗНЫ ОНЫТАБЫЗ

Хөрмәтле «Сабантуй»!

Мин сине бик яратып укыйм. Аеруча мәзәкләрегез, матур шигырьләрегез һәм хикәяләрегез ошый. Мин аларны энемә укыйм. Әнием, «Сабантуй»га язылмыйм, дигәч, без энем белән әллә нишләп киткәбез. Әнигә: «Язып инде, язып инде, әни»,— дип үтенәбез. Әнием: «Бу хәтле ялваргач, язылмыйча булмый инде»,— дип әйтеп, шул көнне үк почтага төшеп, язылa. Газетаның беренче саны килүгә үк, дөньябызны онытып укыйбыз.

Гүзәл МӨХӘММӘТОВА.
Балык Бистәсе, Күгәрчен.

БИК ШАЯН БЕЗ, НАЯН БЕЗ

Исәнмесез, «Сабантуй» редакциясе! Мин сезгә үзебезнең класс турында язып җибәрәм. Безнең класста 9 укучы: 2 малай, 7 кыз. Классыбыз кечкенә булса да, без тату яшибез. Яхшы укырга тырышабыз, тәнәфесләрдә бергә уйныйбыз. Барыбыз да биергә яратабыз. Мәктәптә уздырылган «Исәнмесез, бу — без» дигән концертта үзебезнең осталыкны күрсәттек. Анда без беренче урынны алдык. Классыбызның исеме — «Фантазер». Үзебез турында шаян шигырьләр уйлап чыгардык.

Без туганбыз 85 тә —
Перестройка баласы.
85 тә туганнарның
Кем була соң бабасы?

Октябрят та түгел без,
Пионер да түгел без.
Хыялны канат итүче
«Фантазер»лар бүген
без.

Укытучыбыз бер генә,
Ә үзебез тугыз без.
Арабызда командир юк,
Барыбыз да тигез без.

Җиде кызыбыз матур,
Ике малай бик батыр.
Безнең биегәнне күреп
Бөтен кеше шаккатыр.

Бик тырышсак, барыбыз
да
Бик пөхтә,
бик җыйнак без.
Бер дә мактана
белмибез —
Үзебез бик тыйнак без.

Алсу ИСЛАМГӘРӘЕВА.
Әгерже,
Кичке Таң мәктәбе,
IV класс.

МӘҢГЕ ЯШӘ, УКЫТУЧЫМ!

Мин быел VI Б классында укыйм. Һәр фәнне һәм һәр дәресне зарыгып көтеп алабыз. «Белемне алу суганнан ачы, азыгы балдан татлы» дип юкка гына әйтмәгәннәр. Безнең класс җитәкчесе — Рәмзия апа Нургалиева. Ул инде күп еллардан бирле Иске Йомралы урта мәктәбендә рус әдәбияты укыта. Аның дәресләренең үтеп киткәне сизелми дә кала. Ул аңлашылмаган сүзләрне җиренә җиткереп аңлата.

Рәмзия МИННЕГАЗИЕВА.
Төтеш.

МИН — ӘНИНЕҢ УҢ КУЛЫ

МИНЕМ әнием ничә еллардан бирле фермада сыер савучы булып эшли. Мин дә аңа булышам. Сыерлар савышам, сыер сава торган бидоннарны карап торам, азык салышам һәм сыер асларын чистартам. Анда минем яраткан сыерым бар. Әллә нинди сөйкемле сөяге бар аның! Ул үзе миңа бик ияләште. Мин керсәм, кычкырып сәламли. Ләкин мин аның телен аңламыйм. Эх, миндә дә хайваннар телен аңлый торган тылсым булса икән, минем турыда сөтлебикәләрнең ни уйлаганнарын белер идем. Мин хайваннарны бик яратам. Өйдә дә этләргә бер кәстрүл аш пешереп ашатам.

Мин әнигә өйдә дә булышам. Иденнәр себерәм, урыннар җыям. Әнием миңа алтыннан да кыйммәтрәк!

Азат ӘБЕЛХАНОВ.
Буа, Ташкичү.



ИХ, КЫЗЛАР!..

Ә-әй, кызлар, нәрсә бездән көлеп торган буласыз? Берәр ярамаган эш кылдыкмы әллә? Көлегез, көл, кызлар дип тормабыз, тотып тукмарбыз әле үзегезне!..

Юк ла, анысын шаярып гына әйтәбез, андый малайлар түгел без.

Бездән көлеп торганчы, исемегезне әйтегез. Танышырбыз, дуслашырбыз, укудан кайтканда өйләрегезгә озатып куярбыз үзегезне. Без бит би-ик әйбәт, би-ик шәп егетләр!

Ишетәсезме, кызлар?!



ШАЙТАН АЛЫП КИЛГӘН ӘБИ

КУНАККА килгән әбисеннән оныгы сорый:

— Әби, сине безгә кем алып килде?

— Үзем килдем, балам. Автобуска утырып килдем,— дип җавап бирә әбисе.

— Әни сине шайтан китерде, диגән була тагын!— ди оныгы.

АЯКЛАРЫН СӨРТЕП КЕРГӘН

ТӨРЛЕ-ТӨРЛЕ бөҗәкләр җыелыш җыйганнар. Кыргаяк соңарып кына килгән.

— Нишләп соңардың?— дип сораганнар аңардан.

— Аягымны сөртеп узды вакытым,— дигән кыргаяк.— Ишек башына үзегез: «Аягыгызны сөртеп керегез!»— дип язгансыз ич...

ТЕГЕ ДӨНЬЯДА — ТЕЛЕВИЗОР

Дәү әнисе Лилиягә дога өйрәтә дә болай ди:

— Кызым, шушы доганы укысак, бабаңның кабере нур булып яктыртыр...

— Бабайның анда телевизоры бармыни?— ди Лилия.

«ГОРИШ ӨЙДӘ КАЛДЫ...»

ЭЛЕГРӘК заманда була бу хәл. Безнең авылның бер агае атка утырып, урманга барырга чыга. Юл урыс авылы аша уза. Моның тәмәке төпчеге чабуына төшә дә төтен яна башлый.

— Әй, знакум, горишь!— дип кычкыралар моңа урыслар.

Ә бу агайның абыйсы Гәрәй атлы булып, аңа урыслар, «Гриша, Горишка» дип дәшәләр икән. Бу агай үзен абыйсы белән буташтыралар, күрәсең, дип уйлый.

— Мин Гориш түгел. Гориш өйдә калды,— дип җавап бирә.

«КУЯН, КИРПЕЧ БЕТТЕ!..»

ИКЕ ДУС — куян белән керпе аюны акылга утыртырга уйлыйлар.

Куян әйтә керпегә:

— Әйдә, болай итәбез,— ди.— Агач башына кирпечләр менгереп куябыз. Аю килеп чыгу белән, син шул агач башына менеп, аңа кирпеч белән тондырырсың, ә мин сугышырмын.

Һәм болар шулай эшлиләр дә. Менә бервакыт аю килеп чыга.

— Әй, кылый, нишләп йөрисең монда?— ди ул куянга.

— Сине котәм... Сугышырга!..— ди куян.

Аю көлә:

— Әйдә соң, сугышыйк алайса.

Куян килеп кизәнүгә, агач башыннан аюның башына кирпеч ява башлый. Кирпеч төшкән саен куян:

— Менә сиңа! Менә сиңа! Минем йодрыкның ниндилеген күрдеңме инде?!— дип гайрәтләнә.

Шул вакыт агач башыннан керпе кычкыра:

— Куян дус, кирпеч бетте!

Ул арада куян качып китәргә өлгерә.

ҮЗ КАЛАНЧАСЫННАН КАРАП...

УРАМДА ике эт — Сарбай белән Алабай очрашты.

— Синең хуҗаң исталекләр яза икән. Дөресме?— дип сорады Сарбай.

— Дөрес,— диде Алабай.

— Ә безнең үзе белән ауга барыубызны искә алганмы соң ул язмаларында?

— Юк бугай...

— Алайса, аның истәлекләре ер-р-рунда икән!— диде Сарбай.

Шамил МАННАПОВ
язып алды.

Ренат Харис



Ренат ХАРИС иҗаты турында:

Сибгат ХӘКИМ:

РЕНАТ ХАРИСОВ гадәттәге дүртьюллыклар, сигезьюллыклар авторы түгел. Һәр шигыре аның үз формасын таба, һәркайсы үзенчә бер бөтен... Шигырь формасы — шагыйрьнең дөньяны ничек күрү формасы. Мин яшь шагыйрьнең фикерләвен, шигырьдә эзләнүләрен Дәрдмәндчә-үзенчә дияр идем... Шагыйрьнең көче фикердә, хистә, яза торган предметның эченә, үзәгенә үтеп керә алуында.

1969 ел.

Нил ЮЗЕЕВ:

РЕНАТ ХАРИС — уйлы шагыйрь, уйчан шагыйрь... Ул фикернең көтелмәгәнчә шигъри яңгыравына ирешү юлында иң актив эзләнүчеләрнең берсе... Шагыйрь «кеше кешегә кояш булсын» дигән изге теләктән чыгып эш итә. Ул поэзиянең тематикасын, жанр чикләрен, алымнарын төрләндерү буенча туктаусыз эзләнә һәм тормышның агышы турында уйлана.

1981 ел.

Әхсән БАЯН:

Р. ХАРИС — эчтәлек, сурәт үзенчәлеген, форма төгәллеген, аларның аерылгысызлыгын тоеп, шуны кайгыртып иҗат итүче автор... Р. Харис яңача фикерләве һәм язуы белән аерылып тора. Һәм, әйтергә кирәк, яңалыкка ул аңлы рәвештә омтыла.

1989 ел.

Гариф АХУНОВ:

РЕНАТ ХАРИС иҗатында сабантуйлар, сөлгеләр, Болгар тарихы, атлар язмышы, рәссамнар сала торган төсләр балкышы, халык авыз иҗатыннан килә торган символика — болар барысы да аның туган якларыннан, туган-үскән якларында яшәгән халыкка тамыры белән тоташудан килә.

Музыканы һәм рәсем сәнгатен яхшы белүе, өздереп гармунда уйнавы, халык моңнарының хасиятен тирәнтен төшенеп, шулардан ләззәт таба белүе, өендә үз кулы белән язган картиналары булуы — мәдәният өлкәсендә дә аңа зәвык белән, зур таләпләр куеп эшләргә мөмкинлек тудырды.

1991 ел.

Тәлгать ГАЛИУЛЛИН:

Р. ХАРИС яшьлегендә табылган һәм тормыш тәҗрибәсе белән баетылган юлыннан тайпылмады... Әсәрләрендә ул шәхес фикеренең аңының катламнарына, хисси байлыкларына тирәнрәк үтеп керү алымнарын эзләвен дәвам итә.

1989 ел.

Ринат МӨХӘММӘДИЕВ:

ОЛЫ борчуларда яши Ренат Харис. Басудагы игеннәр өчен булсын, илләр, халыклар һәм Җир язмышы өчен булсын, аның борчуларында мин шагыйрьлек, олы гражданлылык күрәм.

1980 ел.

Вадим КОЖИНОВ (Мәскәү):

НИ В КОЕЙ МЕРЕ не покушаясь на какую-либо полноту «перечня», назову поэтов, чью творческую силу я смог воспринять с особой несомненностью: Размик Давоян (Армения), Мушни Ласурия (Абхазия), Марцелиусс Мартинайтис (Литва), Тайсто Сумманен (Карелия), Ренат Харис (Татария), Атамурад Атабаев (Туркмения), Рамиз Ровшан (Азербайджан).

Для меня ясно, что эти поэты не просто сочиняют стихи, способны в той или иной степени заинтересовать читателей, но вносят весомый вклад в духовное творчество своих народов.

«Литературная Газета», 4 нояб. 1981.

Атнер ХУЗАНГАЙ (Чебоксар):

РЕНАТ ХАРИС пристально вглядывается в разноцветный спектр мира, но его цветовые эпитеты осмыслены по-народному этически... Стихотворение Рената Хариса часто осуществляется так: плавное песенное развитие образа, который все ширится и ширится, а затем резко, пронзительно — укол, щемящая боль в левой стороне груди...

«Дружба народов» № 11, 1984.





БЕЗНЕҢ ЯРАТКАН ӘДИПЛӘРЕБЕЗ

ТОРМЫШ ЮЛЫ

КҮРЕНЕКЛЕ шагыйрь Ренат ХАРИС (Ренат Мәгъсүм улы Харисов) 1941 елның 6 маенда Ульян өлкәсенең Богдашкино районы Зирекле Күл авылында укытучы гаиләсендә туган. Бала чагы һәм мәктәп еллары Татарстанның Буа районында уза. 1958 елда Буа шәһәренең А. В. Луначарский исемендәге урта мәктәбен тәмамлагач, башта Казанга килеп төзелештә эшли. 1959-1963 елларда Казан дәүләт педагогия институтының тарих-филология факультетында югары белем ала. 1963-1964 елларда Арча педагогия училищесында укытучы, 1964-1965 елларда ВЛКСМ өлкә комитетында инструктор, 1965-1971 елларда «Татарстан яшьләре» һәм «Яшь ленинчы» газеталары редакцияләрендә эшли. 1971-1973 елларда Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең җаваплы секретаре вазифаларын башкара. 1973 елдан 1982 елга кадәр Татарстан Мәдәният министры урынбасары булып һәм 1982 елдан 1985 елга кадәр «Казан утлары» журналының баш редакторы булып тора. 1985-1992 елларда партия өлкә комитетында эшли.

1992 елдан — «Татарстан хәбәрләре» газетасының баш редакторы.

«Кеше» ораториясен иҗат иткәне өчен шагыйрь Р. Хариска һәм композитор М. Яруллинга 1972 елда Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге премиясе бирелде.

Р. Харис — Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1972) һәм Каракалпакстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1980) дигән мактаулы исемнәрне йөртә.

РЕНАТ ХАРИС КИТАПЛАРЫ

ТАТАРЧА:

1. Беренче карлыгачлар. Колл. җыентык, 1968. Таткитнәшер.
2. Кайтаваз. 1969. Таткитнәшер.
3. Ак сөлге. 1971. -»-
4. Кошлар — безнең дуслар. 1971 -»-
5. Яңа көн. 1972 Таткитнәшер
6. Бизәк 1974 -»-
7. Баскычлар 1976 -»-
8. Уйлы туйра 1978 -»-
9. Замана эзләре 1981 -»-
10. Алтын төрән 1983 -»-
11. Гүзәл гөмбәз 1985 -»-
12. Ант суы 1987 -»-
13. Матур өй 1988 -»-
14. Хәбәр 1989 -»-
15. Күзгә мәхәббәт 1991 -»-
16. Лап-лап 1992 -»—

УРЫС ТЕЛЕНДӘ:

17. Русские ворота	1977. Москва, Современник
18. Листья	1980. Казань, Таткнигоиздат
19. Войди в дом мой	1980. Москва, Мол. Гвардия
20. Покатился мой клубок	1984. Москва, Сов. писатель
21. Присядь к очагу моему	1985. Москва, Современник
22. Навстречу ветру	1989. Москва, Сов. Россия
23. Солнцепоклонник	1993. Казань, Таткнигоиздат

ТАТАРЛАР

Тарихның, кагылган саен,

әйләнеп көчле бер канга,

Нарат урманы. Р. ХАРИС рәсемнәре.

Ренат Харисның 1 яшь тулгач төшерелгән фотосурәте. Бу фото аның әтисе кесәсендә Бөек Ватан сугышы кырлары аша үтеп, Берлинга барып житеп, әйләнеп кайткан. 1942 ел.

Шагыйрь Р. Харис 1985 елда Әминә ханым Жәлил белән Жәлил поселогында.

Р. Харис студентлык елларында Казан дәүләт педагогия институтының «Әдәбиятчы» газетасында рәссамлык итте. Уртада «Мәгариф» журналының баш редакторы Фәрит Шәрифуллин, «Мәгариф» нәшриятының баш редакторы Жәүдәт Кәлимуллин. 1961 ел.

Мин чыгам ул... Мин ул татар —
һәр заманның тугры улы,
кирәксә, урак, кирәксә,
гадел кылыч тоткан кулы!

Нәкъ башка халыклар кебек —
мин җиңдем дә, җиңелдем дә —
барлык даным һәм хурлыгым
исемемнең җелегендә.

Үткәндә ниләр булмаган!..
Үчләшмимен, үпкәләмим,
тарихның кырыс көннәрен
күзгә бәреп үтсәләр, мин.

Дусларга аркадаш булдым,
дошманнарга сатылмадым.
Кальгаларым тузан булды,
ә исемем ватылмады.

Татар булып кала бирде,
даны-шаны үсә-үсә.
Россия тарихының ул
һәр кузәнәгендә исән...

«Русны бераз тырмаштырсаң,
татар чыгар!..» дигән кемдер.
Халкың газиз түгел икән
шул татарны, яле, күмдер —

так аңа башка бер исем,
йә бүлгәлә кисәкләргә.
Без күнегеп беткән инде
зурны ватып исәпләргә.

Һуннары да, мишәре дә,
болгары да, кыпчагы да,
сувары да, бортасы да,
эреп тарих учагында,

Үткәнемнән баш тартмыйча
яшп бирәмен мин — татар...
Беркем дә табалмас миндә
йөзне кызартырлык таплар.

Кем ул халкы исемендә
ямь тапмаган, тәм тапмаган?!.
Горурларга, кыюларга
татар дигән исем таман.

Күпме дәвер сыйган аңа!
Күпме бәйрәм, якты эшләр,
күпме сугыш, күпме солых,
күпме данлыклы кешеләр!

Кем ул халкы исеменнән
ваз кичүче җиңел генә,
Изрәткеч селте сибүче
бердәмлекнең җилеменә?..

Кемнең сукыр ниятенә
шартлаткыч уй оялаган —
бер бөек бәллүр сабаны
озатмакчы пыялага?!.

Халыклар иседе — алмаз!
Чорлар кырлый аны чарлап...
Татар дигән бриллиантны
киләчәк тә торыр барлап.

Халыкның иң зур байлыгы —
ул исеме һәм Ватаны!
Ассалар да, мин аларны
югалтмамын һәм ватмамын!

Кагылган саен тарихның
коела торыр ярчыгы,
катламнары арасыннан
татар чыгар...
Татар — чыгар!

МАРШЫ

Резеда ӘХИЯРОВА
көе
Ренат ХАРИС
шигыре

Шатланып ачып
керәмен
Мәктәп ишеген—
Белемнең зур көч иконен
Белгән кеше мин.

Кушымта:
Яңгыра, көмеш
кыңгырау,
Безне каршыла—
Кушыл, әйдә, һәм куәт
бир
Белем маршына!

Шатланып ачып
керәмен
Мәктәп ишеген,
Бар көчемне бирен уку —
Минем төп эшем.
Кушымта.

Шатланып ачып керәмен
Мәктәп ишеген—
Ишетәмен
Ватанымның
Йөрәк тибешен.
Кушымта.

Композиторлар арасында Сулдан уңга: Хөснул Вәлиуллин, Ренат Еникеев, Бату Мулеков, шагыйрь Илдар Юзеев, Мәхмүт Нигъмәтҗанов һәм Резеда Әхиярова. 1983 ел.

1967 ел. «Яшь ленинчы» («Сабантуй») газетасының җаваплы секретаре Р. Харис Бакый Урманче остаханәсенең ишегалдында. Уңда — журналист Р. Колосов.

Татарстан Югары Советының Президиумы әгъзасы Р. Харис республиканың дәүләт символлары проектлары авторлары һәм Югары Совет Рәисе Ф. Мөхәммәтшин белән. Сулдан уңга: флаг проекты авторы рәссам Т. Хаҗиәхмәтов, Ф. Мөхәммәтшин, гимн проекты авторы композитор Р. Яхин, герб проекты авторы Р. Фәхертдинов. 1993 ел.

1986 ел. Тукай-Кырлайда, Тукайның 100 еллыгында. Уңда — Мостай Кәрим.

1992 елда төшерелгән бу рәсемдә «Татарстан хәбәрләре» газетасының баш редакторы Р. Харис (уңнан сулга) экономист Л. Абалкин, язучы, юридик фәннәр докторы профессор З. Фәтхетдинов белән.

Р. Харис А. С. Пушкинның оныгының оныгы Григорий Григорьевич Пушкин (уртада) һәм шагыйрь Н. Старшинов белән. 1979 ел. Пушкинские горы.

«Казан утлары» журналы баш редакторы Р. Харис чуваш шагыйрьләре Порфирий Афанасьев (сулда) һәм Юрий Семенов белән. 1985 ел.

Мәдәнният министры урынбасары Ренат Харис композитор Нәҗип Җиһанов белән. 1974 ел.

Әмирхан Еники һәм Р. Харис. 1992 ел.

БАЛА ЧАКНЫ САГЫНУ



КЫЗЫК бит ул кеше дигәнең: бәләкәй чакта аның тизрәк дәү үсәсе килә, ә үсеп җиткәч, бала чагын сагына башлый. Инде олыгаеп, бала чагыннан көннән-көн ерагая барса да, аның хәтер түрендәге шаян-шук малай яки кыз һаман шул килеш, бер дә үзгәрешсез яши бирә. Әнә шулай, инде чәче чаларган, маңгаена тирән сырлар төшкән агай үз исемен йөрткән адашын — бала чактагы үзен — һич оныта алмыйча сагынып, юксынып яши. Язучы Әхәт Мушинский үзенең еракта калган бала чагын юксынудан туган бәләкәй хикәяләрен туплап, Татарстан китап нәшриятында бик матур җыентык бастырып чыгарган. Шунысы кызык — бу китапчыктагы парчалар татар һәм урыс телләрендә. Ул шуның белән балаларга ике телне өйрәнергә дә ярдәм итә. Гомумән, бу китапчыкны зурлар да, нәниләр дә яратып укыр, дип уйлыйбыз. Ә безнең гәзит укучылары игътибарына шушы җыентыкка кергән «Ишеттеңме мине» дигән парчаны тәкъдим итәбез.



ӘНИЕМ җырчы иде. Бик еш кына кичләрен өйдә берьялгызымны калдыра иде ул. Шулай бервакыт радионы ачтым да әниемнең тавышын ишеттем. Ул моңсу гына җырлый иде. Миңа бик тә ямансу булып китте. Күземә яшь тыгылды. Түзмәдем, радиога капландым:

— Әни, әнием, тизрәк кайт инде өйгә-ә...

Җыр тәмамланды. Яшьләремне сөртергә дә өлгермәдем — ишек ачылып китте. Бусагада әнием басып тора.

— Шундый тиз кайтып җиттең!— дип куандым мин.— Чакыруымны ишеттеңме, әнием?!!

Радиода тавыш язмалары булуын да, радионың телефон кебек эшли алмавын да белми идем шул әле ул чакта.





Факил САФИН музыкасы **Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА сүзләре**

Елтыр-елтыр елтырыйм,
Челтер-челтер челтерим,
Гөрләвек мин — кар суы.
Елгага агам туры,
Елларга агам туры...
Елларга агам туры...

Җыр башладым, тыңлагыз,
Кушылып та җырлагыз.
Нурлы яз бит иңсәмдә —
Бии-бии җырлагыз,
Моңаешып тормагыз!
Моңаешып тормагыз!

Йөгерешеп йөрегез,
Яшәү ямен белегез.
Кояшсыз көннәрдә дә
Якты булсын йөзегез —
Елмаегыз, көлегез!
Елмаегыз, көлегез!

Мук исемле малай



«БӘЛӘКӘЙ МУК» исемле әкият героен белмәгән бала дөньяда бар микән?! Башында зур ак чалма, бәләкәй чандыр гәүдәсендә итәге җирдән сөйрәлүче җилән, кулында арыслан башы уелган озын таяк, биленә буылган кушагында озын хәнҗәр кыстырылган, аякларында көймә очлы зур кызыл кәвеш. Үзе орчык буе гына. Шуңа күрә дә аны Бәләкәй Мук дип йөртәләр. Бәләкәй Мук һәм аның башыннан үткән маҗаралары турындагы әкиятне исә бөек немец әкиятчесе Вильгельм Гауф иҗат итеп калдырган. Әле бу көннәрдә генә Казан дәүләт курчак театры шушы әкият буенча спектакль күрсәтте.

Спектакльнең премьерасы булган көнне тамаша залы балалар белән шыгрым тулы иде. Гадәттә бу хакта, имеш, алма төшәрлек тә урын юк иде, дип әйтәләр. Әкият нәни тамашачыларга, әлбәттә инде, бик ошады. Спектакльдән соң мин театрның баш режиссеры Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Илдус **Зиннуров**ка берничә сорау белән мөрәҗәгать иттем.

— Илдус абый, ни өчен бу спектакльне читтән килгән режиссер куйды?

— «Бәләкәй Мук» әкиятен сәхнәләштерү турында без күптән хыяллана идек. Аның әлегә Россиядәге бер генә курчак театрында да куелганы булмады. Без — беренчеләр. Ә бу әкият буенча пьеса иҗат иткән кеше — Юрий Фридман — Мәскәү драматургы, үзе танылган режиссер. Ул Россиянең төрле курчак театрларында, шулай ук чит илләрдә, Америкада спектакльләр куя. Әлбәттә инде, дөньяда исеме мәгълүм режиссерның Казанга килеп спектакль куюы безнең өчен бик мәртәбәле. Беренчедән, ул безнең артистларыбызга зур масштабларда эшләүче режиссердан осталыкка өйрәнергә мөмкинлек тудыра; икенчедән, аларга үз мөмкинлекләренең, осталыкларының ни дәрәҗәдә икәнлеген ачыкларга да ярдәм итә, үз-үзләренә ышанычны арттыра.

— Бу спектакльдә уйнаучы курчакларның күплеге мине хәйран калдырды.

— Әйе, курчакларның күплеге һәм төрлелеге белән дә спектакль башкалардан аерылып тора. Декорацияләр гаҗәеп бай, зәвык белән һәм җыйнак итеп эшләнгән. Аларны театрыбызның рәссамы Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Александр Губский эшләде. Спектакль музыкаль яктан да бик уңышлы бизәлде. Аның буеннан-буена диярлек шәрык музыкасы яңгырый. Аны композитор Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Фуат Әбүбәкерев туплады. Кыскасы, әкият һәм бизәлеш, һәм музыкаль яктан уңышлы чыкты дип әйтергә мөмкин.


— Әлбәттә инде, спектакльнең төп башкаручылары — артистлар хезмәтен дә телгә алып китәргә кирәктер.

— Әйе, артистларыбыз да Мәскәүдән килгән режиссер алдында югалып калмадылар, барлык осталыкларын күрсәтеп, тырышлыкларын куеп уйнадылар.

Тамашачылар сәхнәдә эреле-ваклы утыздан артык курчак күргәннәрдер. Ә аларны нибарысы алты артист җанландырды.

Әйе, Казан дәүләт курчак театры нәни дусларын яңа тамаша белән шатландырды. Моңа кадәр балалар «Бәләкәй Мук»ны китаптан укып кына белсәләр, хәзер инде курчак театры сәхнәсендә аның үзен күрергә дә мөмкин. Моның өчен бары тик әлеге спектакль буласы көнне театрга барырга гына кирәк.

Рафис КОРБАН.





ҖИЛ

Тышта салкын җил өрә,
Төрле якка йөгерә.
Ничек шулай өлгерә?
Йә, әйтегез, кем белә?

КҮМӘЧ

Мин иртән иртүк
тордым.
Юынырга тотындым.
Урынны җыеп куйдым,
Ашарга дип утырдым.

Әни бирде бер күмәч,
Тәмле, үзең үстергәч.
Әти белән көн саен
Мин, табып бирәр җаен,
Китәм иртүк басуга,
Китәм иген урырга.

Гөлшат КОНОВАЛОВА.
Лениногорск,
Урдалы мәктәбе.

АВЫЗЫНА СУ КАПКАН

Әй, уйный Рафис көн буе,
Рәхәтләнеп, йөгереп.
Дәресләрен әзерләргә
Булдыралмый өлгереп.

Укытучы сораганда
Әйтергә сүз тапмады.
Авызына су капканмы?
Кабуын ул капмады.

Бөкрәя дә тора ул
Сорау билгесе сыман.
Җавап бирми,
дәшми торып
«Ике»ле ала һаман.

Наил ВӘЛИЕВ.
Арча,
Урта Курса мәктәбе.

Баш мөхәррир
Роберт МИҢНУЛЛИН
Редколлегия: Шәүкәт ГАЛИЕВ, Илдар ЮЗЕЕВ, Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ, Ләлә ГЫЙМАДИЕВА (җаваплы секретарь), Госман САДӘ (баш мөхәррир урынбасары).



«Сабантуй»ны оештыручылар — Татарстанның Халык Мәгарифе министрлыгы, Яшьләр оешмалары советы, Балалар фонды һәм редакциянең хезмәт коллективы. 1924 — 90 елларда «Яш ленинчы» исеме белән чыкты.
Индекс — 54124. Тираж 13793



Адрес: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Телефоннар:
49-36-86, 49-36-90,
49-36-77, 49-36-88,
49-36-94, 53-57-37.

Ярдәм итәргә теләсәгез: р/счет 700161998/2345716 в Волжско-Камском акционерном банке РКЦ ГЦБ г. Казани МФО 265005 «Для фонда редакции».



Заказ 1812
Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты типографиясендә басылды.
Басарга кул куелды: 1995 ел, 5 апрель, 15 сәгать.